**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Корноухово авыл җирлеге составына керүче Корноухово авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

29 ноябрь, 2021 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2021 елның 29 ноябрендә “2022 елда Корноухово авыл җирлегенең Корноухово авыл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләр:

- Корноухово, Зюзино, Шетнев-Чирмешән авылларында урам юлларын кышкы чорда карап тоту (тору) – кардан арындыру;
- Корноухово авылында ЭЦВ 6-10-80 маркалы 1 данә тирәнлек насосы сатып алу һәм урнаштыру;
- юл-төзелеш материаллары сатып алу һәм Корноухово авылында Яр буе урамының 400м озынлыктагы юл кишәрлеген ремонтлау;
- юл-төзелеш материаллары сатып алу һәм Корноухово авылында Яшел урамының 300м озынлыктагы юл кишәрлеген ремонтлау;
- Корноухово авылында Совхоз, Эшчеләр поселогы урамнарында вак таш түшәлгән юл кишәрлекләрендәге чокырларны ремонтлау эшләре;
- Корноухово, Шетнев-Чирмешән һәм Зюзино авыллары урамнарында юл читләрендәге чүп үләннәрен чаптыру;
- Корноухово, Шетнев-Чирмешән һәм Зюзино авылларында урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, алыштыру һәм карап тору;
- Корноухово авылында су үткәрү челтәрләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, запас частьләр сатып алу, шартнамә нигезендә хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Корноухово авылында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга куелган стеланы ремонтлау

өчен тотуга Сез ризамы?

“ЯКЛАП” “КАРШЫ”

дигән мәсьәлә көн тәртибенә куелып уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде .

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 230 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны – 144 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында 143 катнашучы “Яклап” позициясе өчен тавыш бирде;
“Каршы” позициясе өчен җыенның 1 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Корноухово авыл җирлеге составына керә торган Корноухово авылы торак пунктында гражданнарның җыенын **УЗДЫ** дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен **ДӨРЕС** дип **танырга.**

2. “2022 елда Корноухово авыл җирлегенең Корноухово авыл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан гайре, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләр:

- Корноухово, Зюзино, Шетнев-Чирмешән авылларында урам юлларын кышкы чорда карап тоту (тору) – кардан арындыру;
- Корноухово авылында ЭЦВ 6-10-80 маркалы 1 данә тирәнлек насосы сатып алу һәм урнаштыру;
- юл-төзелеш материаллары сатып алу һәм Корноухово авылында Яр буе урамының 400м озынлыктагы юл кишәрлеген ремонтлау;
- юл-төзелеш материаллары сатып алу һәм Корноухово авылында Яшел урамының 300м озынлыктагы юл кишәрлеген ремонтлау;
- Корноухово авылында Совхоз, Эшчеләр поселогы урамнарында вак таш түшәлгән юл кишәрлекләрендәге чокырларны ремонтлау эшләре;
- Корноухово, Шетнев-Чирмешән һәм Зюзино авыллары урамнарында юл читләрендәге чүп үләннәрен чаптыру;
- Корноухово, Шетнев-Чирмешән һәм Зюзино авылларында урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, алыштыру һәм карап тору;
- Корноухово авылында су үткәрү челтәрләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, запас частьләр сатып алу, шартнамә нигезендә хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Корноухово авылында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга куелган стеланы ремонтлау

өчен тотуга Сез ризамы? “

дигән мәсьәлә буенча карарны **кабул ителгән дип танырга.**

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Корноухово авылы, Совхоз урамы, 3 йорт; Шетнев-Чирмешән авылы, Совет урамы, 21 йорт; Зюзино авылы, Үзәк урам, 6а йорт; Наумово авылы, Наумово урамы, 3 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм шулай ук http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Г.С Гумашян

Корноухово авыл җирлеге Башлыгы: Г.С Гумашян